Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы балаларга өстәмә белем муниципаль бюджет учреждениесе
«Яңа Кенәр балалар иҗаты Йорты»

**"Раслыйм"**
**Директор: Х.Х.Зарипов.**
**20.11.2017.**

# "Уңган хуҗабикәләр "бәйгесе

**("Оста куллар" түгәрәгендә шөгыльләнүче балалар өчен профориентацион юнәлештәге чара программасы)**

**Үткәрү вакыты: 21 ноябрь 2017 ел.**



**I нче ктегорияле өстәмә белем бирү педагогы**
**Загидуллина Г.В.**

**2017 ел.**

# Уңган хуҗабикәләр бәйгесе.

**Максат:**

- Укучыларда коммуникатив культура тәрбияләү;
- Үзара ярдәмчеллек, үз фикерен әйтә белү осталыгы тәрбияләү;

Залның бизәлеше: “Тормышның язы һәм чәчәге – хатын - кызлар”, “Тышкы матурлык эчке матурлыкның һәм пакълекнең чагылышы булырга тиеш” В.Г. Белинский”, “Кешенең бөтен нәрсәсе дә, гүзәл булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, уйлары да, күңеле дә. А.П. Чехов” дип язылган плакат – лозунглар эленеп тора.

Балаларны һөнәр сайлауга әзерләү

**Катнашалар:**

- 5-әр кешелек 2 команда;
- алып баручы;
- жюри – 3 кеше

Өй эше: команда исеме, девиз, бер музыкаль номер.

Җиңел музыка астында алып баручы чыга.

**Алып баручы.** Исәнмесез, хөрмәтле тамашачылар! Без бүгенге кичәбезне гүзәл һәм уңган кызларга багышлыйбыз. Кичәбезнең исеме дә “Уңган хуҗабикәләр!” дип атала.

Әйдәгез, хөрмәтле тамашачылар, кул чабып, кызларыбызны сәхнәгә чакырыйк.

Хәзер мин сезне кызлар белән таныштырып үтәм. Менә күрәсез, дуслар, сәхнәдә кызларның иң уңганнары, иң булганнары, иң гүзәлләре генә.

Менә бу өстәл артында жюри әгъзалары утыра. Жюри әгъзаларына безнең үтенеч шул, дөрес бәя биреп барсыннар иде. (Жюри әгъзалары белән таныштырып үтә).

Без беренче эш итеп командалар белән танышырга тиешбез. Сүзне кызларга бирәбез.

**Конкурслар:**

**1.** Безнең оешмада иң уңган, иң булган кызлар гына шөгыльләнә. Иртән иртүк мәктәпкә чыгып китәргә кирәк. Үч иткәндәй кечкенә сеңлем йокыдан торып килә. Дәрес башланырга санаулы минутлар гына... Ә аны киендерәсе, юындырасы бар, чәчен тарап үрәсе дә бар. Сеңелләребезне киендерәбез.

**Концерт номеры: җыр**

**2.** Гомер буе ашлы – сулы яшәүнең сере изге йолаларыбызның үтәлүеннән түгелме соң?

Туй, бәби ашлары – токмачлы аш, авыл мичендә пешкән икмәк, чәк – чәк, гөбәдия, кош теле, коймак.

Ә менә, токмач кисү буенча иң уңган кыз исеменә кем лаек булыр? Кызларыбыз үзләренең аш – суга осталыкларын, булганлыкларын токмач кисеп күрсәтергә телиләр.

**Концерт номеры: нәфис сүз**

**3.** Татар халкы борын – борыннан бик кунакчыл. Ул кунакларны еш җыю белән бергә, үзе дә кунакка йөрешә, аның табыны мул, ризыклары да күп төрле була. Шундый ситуация : кинәт кенә кунаклар килеп төште. Ә суыткычта берничә төрле генә ризык бар. Хәзер кызларыбыз кунак өстәле хәзерләү осталыгын күрсәтерләр, бу хәлдән ничек

чыгарлар. Ризык төрләре.1. Бәрәңге , казылык, сыр, кәбестә, алма, майонез. Кызлар бу ризыклардан салат әзерләргә тиешләр. Салатка исем сайлыйлар.

**Концерт номеры: бию**

**4.** Пешкән ризыкларны матур итеп өстәлгә бирү үзе осталык сорый. Әгәр дә матур эскәтер дә җәйсәк ничек күңелле булыр .

5**.** Бирем модага кагылышлы. Хәзерге мода бит күптөрле. Кызлар, сез хәзер бераз алгарак китеп, алдагы ел модасын тасвирлап күрсәтегез. Менә сезгә шуның өчен шарфлар, төрле бижутерия. (Соңыннан һәрберегез үзегез тасвирлаган модага кыскача аңлатма бирегез. Модагызның исеме дә булырга тиеш).

Кызлар бу эштә мәшгуль булган арада мин сезгә “Мода” турында әйтеп үтәм:

Мода “кинәт” кенә, буш урында барлыкка килмәгән. Ул һәрвакыт яшәгән. Традиция – ата – бабаларыбыз барлыкка китергән һәм буыннан – буынга тапшырган көнкүреш ныклыгын саклауга, тормыш рәвешен, зәвык һәм гадәтләрне кабатлауга табигый ихтыяҗларны канәгатьләндерү булса, мода да кешенең яңалыкка, үзгәрешкә табигый ихтыяҗын канәгатьләндерү ул.

**6**. Чыгып киткәндә генә күреп калдым. Төймәм төшкән бит. Төймә тагу конкурсы.

**7.** Татар хатын – кызлары кунакчыл, тырыш, эшчән, кайчак – шук, шаян, кирәк чакта өлгер – җитез, булдыклы бит алар...кирәк булса ирләр эше дип тә тормыйлар.
Чүкеч белән кадак кагу.

**Концерт номеры: җыр**

8**.** Җеп эрләү һәм оекбаш бәйләү таныш шөгыль . Хәзер сезнең кул эшенә осталыкларыгызны тикшереп китәрбез. Кем кул эшенә оста- рәхим итегез! Һәр командадан икешәр уенчы чакырыла. Бер уенчы карандашка җеп чорнарга, ә икенче уенчы киресенчә сүтеп йомгакка чорнарга тиеш . Кайсы тизрәк биремне үти ,шул җиңүче була. Йомгакның сыйфаты исәпкә алына.

9. Өй эше. Кызлар алдан алып килгән ризыклары ярдәмендә торт бизиләр.

**Безнең бәйгебез ахырына якынлашты.Нәтиҗә ясар өчен сүзне җюрига бирәбез.**

Кызларыбызга безнең күңелне ачканнары, ял иттергәннәре өчен рәхмәт белдерәбез, аларга укуларында уңышлар, сәламәтлек, шатлык һәм бәхет телибез.

Шушының белән “Уңган хуҗабикәләр.”бәйгесе тәмам. Игътибарыгыз өчен рәхмәт.



